КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 декабрь г.Казань № 1100

Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында

Яңа туган балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән Татарстан Республикасында даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләр тәэмин ителә дип билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәне;

Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын алу хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләмен исәпләү һәм гаиләнең җан башына уртача кереме күләме хакындагы белешмә кәгазен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне.

3. Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәне куллану буенча аңлатма бирү түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе өлешендә – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын алу хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләме хакындагы белешмә кәгазен бирү тәртибе өлешендә – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

бүләк комплекты составы өлешендә – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.

4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин